**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Министерство образования Республики Мордовия**

**Ромодановский муниципальный район**

**МБОУ "Белозерьевская средняя общеобразовательная школа"**

| | | |
|---|---|---|
| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
| Методобъединение | Зам.директора по УВР | Директор школы |
| ________________________ | ________________________ | ________________________ |
| Абдрашитова Л.Р. | Манеева Л.Р. | Киреева Э.И. |
| Протокол №1 от «30» августа2023 г. | Протокол №1 от «30» августа2023 г. | Приказ № 93 от «31» августа2023 г. |

**Рабочая программа**
**учебного курса « Родная (татарская) литература»**
**в 3 «А» классе**
**УМК «Школа России»**


**Составитель:**
**Бикмаева Гульсина Няиловна**
**учитель начальных классов**
**МБОУ "Белозерьевская СОШ"**


**Белозерье**
**2023 г**

**Аңлатма язу**

**Эш программасының статусы**

3нче сыйныф өчен Гарифуллина Фирдәвес Шафиковна, Мияссарова Илсөяр Хәбибулловна тарафыннан эшләнгән ( Казан, Мәгариф, 2013), ТР Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә(ике кисәктән тора) нигезләнеп төзелде.Дәреслек “Перспектив башлангыч мәктәп” концепциясенә нигезләнә һәм гомуми белембирү Федераль белем стандарты, татар теленнән гомуми белембирүнең гамәлдәге дәүләт стандарты таләпләренә туры килә.

**1.Эш программасының эчтәлеге**

***Рус мәктәбендә белем алучы татар балаларына әдәбият укытуның төп максаты һәм бурычлары***

-уку күнекмәләрен үстерү һәм камилләштерү;
-укуга, китапка кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү;
-матур әдәбият, аның авторы, әсәрнең жанры, персонажы турында күзаллау булдыру;
-дөрес һәм бәйләнешле әйтмә һәм язма сөйләмгә өйрәтү;
-әдәби әсәрләр йогынтысында үз-үзеңне әдәпле тоту күнекмәләре булдыру;
-эчтәлеге укучыларга якын булган әкиятләр, татар халкының мәзәкләре, мәкальләре һәм әйтемнәре, табышмаклар һәм тел шомарткычлар аша укучыларда зирәклек, тапкырлык сыйфатлары тәрбияләү.

***Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы.*****Тыңлап аңлау.**Сөйләмдәге сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аңлау, аларны бер-берсеннән аеру, әйтелгән фикердәге мөһимрәк булган вакыйгаларның эзлеклелегенә төшенү.

**Сөйләү.**Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен гамәли үзләштерү. Укуга һәм көндәлек тормышка кагылышлы темалар буенча әңгәмә кору. Укылган текстка сорау кую, аның эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җавап бирү, планын төзү.Укучыларга якынрак темалар буенча сөйләшү.
Сөйләм этикеты үрнәкләреннән дөрес файдалану.

**Уку.** Әкиятләрне, кечкенә хикәяләрне, дәреслектәге текстларны аңлап, дөрес, йөгерек итеп укый белү. Текстның төп фикерен аңлап, темасын билгели алу, кирәкле урыннарны сайлап уку. Гади план төзеп, текстның эчтәлеген сөйләү һәм укучының текстка мөнәсәбәтен белдерү.

***3 нче сыйныфны тәмамлаган татар балалары үзләштерергә тиешле белем-күнекмәләр.***

-укытучының өйрәнгән материалга нигезләнгән сөйләмен тыңлап аңлау;
-текстны тыңлаганнан соң, төп фикерне башкаларыннан аера белү;
-татарча сөйләмне тыңлап, сүз һәм җөмлә чикләрен билгеләү;
-балалар өчен нәшер ителгән китаплар, газета-журналларны, әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес, йөгерек, аңлап уку.

**Укыту фәненең уку планында тоткан урыны**

Укыту планында “Белозерье урта мәктәбендә” каралганча, уку дәресләре өчен эш программасы атнага 2 сәгать исәбеннән елга 68 сәгатькә төзелде.

**Уку күнекмәләре**.

Дөрес,аңлап,тиешле дәрәҗәдә йөгерек һәм сәнгатьле уку.

Интонацияне текст эчтәлегенә бәйле рәвештә сайлау.Уку тизлеге 1 яртыелда – 60 сүз, уку елы ахырында – 75 сүз.

Уку тизлеген сүзне тулы һәм төгәл күрергә, тиз аңларга өйрәтү исәбенә үстерү. Эчтән уку алымына зур күләмле һәм күптөрле текстларны укытып өйрәтү. Сәнгатьле уку осталыгын камилләштерү.Авазларны дөрес һәм ачык әйтүгә ирешү. Укыганда орфоэпия нормаларын үтәү, уку тизлеген эчтәлеккә бәйле рәвештә сайлау, аны арт-тыра һәм киметә белү, сөйләм максатына карап, тавышны көчәйтеп һәм пышылдап уку. Әдәби әсәрләрне рольләргә бүлеп укырга һәм сәхнәләштерергә өйрәтү.Сәнгатьле укуга хәзерләнә белү: эчтәлекне аңлау,сурәтләнгән күренешләрне ачык итеп күз алдына китерү,ритмын отып алу,башкару максатын аңлау.

**Тест өстендә эшләү** .

Әсәрне тыңлаганда һәм укыганда төп фикерне тотып ала белх, хикәяләхнең логикасын,Тексттагы интонацион һәм мәгънәви бәйләнешләрне аңлау. Вакыйгаларның эзлеклелеген , үзара бәйләнешен билгеләү.Сүзле картина элемент-лары кертеп, укылган текстның эчтәлеген тулысынча,сайлап. Һәм кыскача сөйләү, җавапның дөреслелеген текттан өзекләр укып раслау.Текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү, төп фикерне табу. Укытучы ярдәмендә план төзү,эчтәлеген сөйләү.Сурәтләү өчен автор кулланган сүзләрне табу.Әсәр геройларының эш-кыланышларына,УЙ- ХИСЛӘРЕНӘ бәя бирү.Әдәби әсәрнең тел чараларына игътибарлы булу.Андагы сурәтләү чараларын аңлату.Шигъри сүзгә игътибарлы булу, тексттан эпитет, ча-гыштыру,метафорыларны табу.

Мәктәп,сыйныф тормышын күзәтәләр нәтиҗәсендә хикәяләр төзү.Үз сөйләмеңне планлаштыра белү,соңыннан тикшерү.сөйләм максатын исәпкә алып, төзәтмәләр кертү.Әкият һәм хикәяләр сюжетына үз вариантларыңны уйлап табу.,әсәр геройла-рының урыннарын алыштыру.аларны гадәти булмаган хәлләргә кую. Сюжет үсешен алдан билгели алу,исеме һәм башламы буенча китапның темасын,якынча эчтәлеген билгеләү.

Балалар белергә тиешле әдәби жанрлар:әкият һәм хикәя, шигырь һәм мәсәл,халк авыз иҗаты әсәрләре.

**Уку һәм балалар китабы белән эшләү**.

Дәреслекнең эчтәлек өлешеннән әсәрләрне исеме буенча табу,бер темага караган текстларны аеру.

Тәкъдим ителгән китаплар исемлеге белән эшләү.Китап авторы белән танышу,аның исем – фамилиясен,китаптагы портретын табу; берничә китабын чагыштырып,иҗатының темасын билгеләү,авторның үзе турындагы әсәрләрен ачыклау.Укылган китап буенча әңгәмәдәдә катнашу.сорауны ишетә,аңлау һәм темага бәйле рәвештә җавап бирү;үз фикереңне дәлилләү өчен әсәрдән өзекләр китерә белү.

Авторы ,исеме һәм аннотациясе буенча укылмаган китап турында кечкенә хикәя язу. Укылган китап турында, темасын,геройларын,вакыйгаларын чагылдырып һәм үз мөнәсәбәтеңне белдереп,4-5 җөмләдән торган хикәя язу.

Яттан өйрәнү- ел дәвамында өйрәнелгән төрле авторларның 10-12 шигыре.

**Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

- аңлап, дөрес итеп укырга, бер минут эчендә кычкырып 75 сүзле текстны йөгерек укырга;
- сәнгатьле итеп: интонация һәм паузалар ясап, тиешле күләмдәге текстны яки шигырьне укырга;
- китап турында мәгълүмат бирергә: автор, әсәр исеме, тышлыгы, титул бите, эчтәлеге иллюстрация - рәсемнәре турында әйтергә;
- халык авыз иҗатыннан мисаллар китерергә;
- төрле әдәби жанр әсәрләреннән мисаллар китерергә;
- аерым темаларга караган әсәрләрнең (табигать, тереклек, балалар һ.б.) авторларын әйтеп мисаллар китерергә;
- тәкъдим ителгән текстка сораулар куярга;
- текстны мәгънәви өлешләргә бүләргә;
- халык авыз иҗаты жанрларын чагыштырып, аермаларын әйтергә;
- әдәби жанрларны чагыштырырга, аерырга;
- әсәрнең идеясен кыскама характерлап әйтергә;
- таныш булмаган китапның исеменә, эчтәлегенә, рәсемнәренә карап, нәрсә турында икәнлеген якынча әйтергә;

-тыңлап, әсәрнең жанрын билгеләргә;
-план буенча әсәрнең эчтәлеген сөйләргә;
-бирелгән рәсемнәрне тәртипкә салып, әсәрдәге вакыйгаларның эзлеклелеген табарга; Уку тизлеген сүзне тулы һәм төгәл күрергә, тиз аңларга өйрәтү исәбенә үстерү. Эчтән уку алымына зур күләмле һәм күптөрле текстларны укытып өйрәтү. Сәнгатьле уку осталыгын камилләштерү.Авазларны дәрес һәм ачык әйтүгә ирешү. Укыганда орфоэпия нормаларын үтәү, уку тизлеген эчтәлеккә бәйле рәвештә сайлау, аны арт-тыра һәм киметә белү, сөйләм максатына карап, тавышны көчәйтеп һәм пышылдап уку. Әдәби әсәрләрне рольләргә бүлеп укырга һәм сәхнәләштерергә өйрәтү. Сәнгатьле укуга хәзерләнә белү: эчтәлекне аңлау,сурәтләнгән күренешләрне ачык итеп күз алдына китерү,ритмын отып алу,башкару максатын аңлау.
-текстта махсус тел-сурәтләү чараларын: эпитет, чагыштыру, сынландыруны, шигырьдә рифманы табарга, аңлатырга;
-китап турында библиографик мәгълүмат бирергә;
-балалар өчен чыга торган газета-журналлар турында мәгълүмат бирергә;
-әсәргә кыскача аннотация төзи белергә;
-ирекле темагахикәя төзергә, сөйләргә;
- 8 әсәрне яттан сөйләргә (шигырь яки хикәяләп язылган әсәр)

**Укучыларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә төп таләпләр**

3 нче сыйныф ахырында укучылар аңлап, дөрес, сәнгатьле, кычкырып һәм эчтән уку күнекмәләренә ия булырга тиеш. Кычкырып уку тизлеге — 1 минутка 75 сүз.

**Укучылар эшли (башкара) алырга тиеш:**

— укылган текстның эчтәлеген аңлау һәм аның темасын билгеләү;

**Укучылар белергә тиеш:**

— яттан 10 – 12дән дә ким булмаган шигырь белү;
— 2—3 зур күләмле әсәрнең (фольклор һәм мәшһүр язучыларның әсәрләре) исемен, темасын һәм сюжетларын;
— 6—7 халык әкиятенең эчтәлеген, 10 нан артык мәкаль һәм әйтем, 2—3 тапкыр тәгъбир (аларның мәгънәсен аңлау һәм нинди ситуацияләрдә урынлы кулланылганнарын әйтү).

## 2.Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр.

-шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларынкамилләштерү, күпмилләтле милләтебезгә карата ярату хисләре, татар әдәбиятына һәм башка халыклар әдәбиятына, мәдәниятенә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;
-төрлемәглүмат чараларын танып белү һәм аралашу мәсәләсен хәл иткәндә(сүзлекләр,энөиклопедия, Интернет ресурслар һ.б.)куллану;
-милли горурлык, гражданлыкхисләре формалаштыру;
-әхлак нормаларын, җәмгыяттә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;

**Метапредмет нәтиҗәләре**

“Әдәбият” курсын өйрәнүнең метапредмет нәтиҗәләре булып, универсалҗ уку-укыту гамәлләре санала(УУГ).

**Коммуникатив УУГ(КУУГ)**

-төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
-үз фикереңне тексттан өземтәләр китереп, дәлилли белү;
-укылган. тыңланган әсәрләр буенча сораулар бирә белү;
-башкаларнытыңлый, кирәк булганда үз фикереңне үзгәртә белү;

**Предмет нәтиҗәләре**

**Танып белү өлкәсендә**

-төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку;
-сәнгатле уку;
-әсәрләрне анализлау һәм шәрехләү;
-план төзү;
Уку – сөйләм эшчәнлегенең бер төре. Процесс буларак ул барлык телләрдә дә бертөрле: сүзнең график формасын аваз формасына күчерү. Уку – шул вакытта танып белү эшчәнлегенең нигезе, аның төп ысулы. Шуңа күрә уку дәресләренең төп бурычы – укучыларда йөгерек, аңлы, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру, текст һәм китап белән эшләү осталыгы тәрбияләү. Уку тизлеге – укучыларның яхшы укуына шарт булып торган иң мөһим фактор. Уку процессында оператив хәтер һәм тотрыклы игътибар үсеш ала, баланың акыл хезмәтенә сәләте исә шушы ике күрсәткечкә бәйле.
Куп укыган бала тиз укый. Шуңа күрә башлангыч сыйныфларда китап укуга һәвәслек тәрбияләү, әдәбиятны сүз сәнгате буларак кабул итәргә өйрәтү мөһим мәсьәлә булып тора. Уку күнекмәләре укуга һәвәслек белән бергә генә үсеш алырга мөмкин.
Моңа бәйле рәвештә II-IV сыйныфларда уку дәресләрендә мондый бурычлар өстәлә:

- баланы матур әдәбият әсәрләре дөньясына алып керү һәм сүз сәнгатенең образлылыгын аңларга өйрәтү;
- төрле жанрдагы әдәби әсәрләр белән таныштыру;
- яңа китаплар белән танышуга, элеккеләрен кабат укуга теләк тәрбияләү, китап укудан ләззәт, хозурлык табарга өйрәтү;
- әсәрне уку – аның “серенә” төшенү икәнлеген аңлату, авторның позициясен, язылганга мөнәсәбәтен ачарга өйрәтү, автор белән аралашу өчен уку;
- әсәрдәге сүзне укучының игътибар үзәгенә кую; аны образлар тудыру алымы, авторның фикерен, уйларын, хисләрен белдерүче чара, автор ачкан могҗиза буларак кабул итәргә өйрәтү;
- укучыларның әсәрне эмоциональ-эстетик кабул итүенә ирешү; хисләр сферасын әхлакый, рухи матурлык тойгылары белән баету;
- әдәби әсәрләрне укыганда, балаларның акылын, ихтыярын, хисләрен һәм рухи ихтыяҗларын үстерү.

Сүз сәнгате белән таныштыру максатыннан, II-IV сыйныфларда әдәбият белеменнән мәгълүматлар бирелә: автор турында белешмә, әдәбиятның төрле жанрлары һәм аларның үзенчәлекләре, әсәрнең темасы, төп фикере, фольклорның кече жанрлары үзенчәлекләре, чагыштыру, эпитет, метафора, җанландыру, рифма, строфа. Ләкин бу терминнарны үзләштерү һәм аларны тексттан таба белү төп максат түгел, алар әсәрне тирәнрәк аңлау өчен кулланылалар.

Әдәби әсәрне тиешенчә кабул итү укучының тормыш тәҗрибәсенә бәйле. Укылганны бала үзенә үлчәп карый, үз фикерен, эш-кыланышларын әсәр героеныкы белән чагыштыра, дөньяны ничек аңлавына карап, образ тудыра, барысын үз аңы, үз тәҗрибәсе аша үздыра. Әсәрне кабул итү, аңлау өчен вакыт таләп ителә. Укучыга әсәрнең сәнгать тирәнлеге беренче тапкыр укыганда ачылмый, кабат укыганда гына яңа ассоциатив бәйләнешләр туа. Кабат укуны оештырганда, биремнәр катлаулана барырга тиеш. Шул очракта гына балалар әдәби әсәрне кабул итү һәм аңлау ягыннан сыйныфтан сыйныфка үсәләр.

Сәнгатьле уку- әсәрне аңлату ысулы. Ул – әсәрне (геройларның) халәтен, аларның кичерешләрен, авторның темага эчтәлеккә мөнәсәбәтен, язылганның матурлыгын) тирәнтен аңлау нәтиҗәсе. Башта сәнгатьле укырга балалар укытучыга охшатып кабатлап өйрәнәләр, соңыннан кайбер әсәрләрне мөстәкыйль рәвештә сәнгатьле укый алалар.

Программаны нәтиҗәле үтәү дә балаларның тормыш тәҗрибәсе туплавына бәйле. Дәресләрдә балалар күңел үсү һәм кәеф китү, ярсу һәм өметсезлек, канәгатьлек хисе һәм кызыклы фикер яки әсәр героеның эшләнгән эшеннән күңел булу тойгыларын кичерергә тиеш.

## 3.Календарь-тематик планнаштыру, 3нче сыйныф

| № | Дәрес темасы | Сәг. саны | Дәрестә кулланган алымнар | Үзләштерү дәрәҗәсе | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | План | Факт |
| **Сау бул,җәй,исәнме мәктәп!** | | | | | | |
| 1 | Сау бул,җәй! Р.Вәлиев.<br>Балалар эше. М.Гафури. | 1 | Җәйге каникуллар,җәй турында сөйләү. | Шигырь ритмын отып алу | | |
| | | | Шигырьнең тормыш өчен кирәкле сүзләрен табып уку. | Вакыйгаларның эзлеклелеген, үзара бәйләнешен билгеләү. | | |
| 2 | Китап.һәм балалар. М.Гафури.<br>Китап .В.Нуриев | 1 | Табышмакларныңҗавапларын әйтү, сүзтезмәләрне тулыландыру. | Җавапның дөреслеген тексттан өзекләр раслау | | |
| | | | Хәзер китапларны ничек бастыралар? Шул сорауга җавап табу. | Текстны мөстәкыйль рәвештә мәгънәле кисәкләргә бүлүһәм аларда чагылдырылган төп фикерен таба алу | | |
| 3 | Кызыклы шәкерт. Г.Тукай.<br>Былбыл сайратамХ.Халиков. | 1 | Шигырьне рольләргә бүлеп уку. | Шигырь ритмын отып алу | | |
| | | | Шигырь белән автор нәрсәәйтергә теләгәнен әйтә беләү | Шигырь ритмын отып алу | | |
| 4 | Туган тел.Г.Морат<br>Б.с.ү Сынлы сәнгать музеенда.И.В.Рафиков. “Әй,туган тел!” | 1 | Шигырьне ятлау. | Шигъри сүзгә игътибарлы, сизгер булу | | |
| | | | И.В.Рафиковның “Әй,туган тел!”картинасы белән танышу,Картинаны сүзләр белән сурәтли белү. | Танышкан картина буенча әңгәмәдә катнашу | | |
| 5 | Кечкенә Ринат.Р.Гыйззәтуллин.<br>К.Нсыйри “Акыллы һәм яхшы холыклы” | 1 | Өзекнең эчтәлегенен текстка якын итеп сөйләү. | Укуга омтылу,китапларны саклап тота белү. | | |
| | | | Өзекнең эчтәлегенен текстка якын итеп сөйләү. | Сурәтләнгән күренешне ачык итеп күз алдына китерү | | |
| 6 | Сау бул,җәй,исәнме мәктәп! бүлеген йомгаклау. | 1 | Укылган әсәрләрне искә төшерү,чагыштыру,дәлилләү. | Әдәби әсәрнең тел чараларында игътибарлы булу, андагы сурәтләү чараларын аңлау | | |
| **Энже чәчтем,энже җыям...** | | | | | | |
| 7 | Табышмак-зиһен ачкычы<br>Табышмаклар нинди була? | 1 | Халык аваз иҗаты әсәрләре – табышмаклар белән танышу. | Табышмакларныңҗавапларын таба белү. | | |
| | | | Табышмакларны төркемнәргә аера | Табышмаклар уйлап чыгара белү | | |

**Әдәбиятисемлеге:**

1. “Мәгарифтурында” Россия Федерациясенең Законы ( “Закон об образовании”Закон Российской Федерации)

2. “Мәгарифтурында” Татарстан Республикасы законы (6,7,10,32 статья)

3. Насибуллина Р.Н. “Татарский язык в таблицах и схемах для русскоязычных учащихся начальных классов”, Казань, “Гыйлем” нәшрияты, 2008 ел

4. Рус мәктәпләрендәге рус төркемеукучыларына татар теленнәнгомумибелембирүнеңдәүләт стандарты. Казан, “Мәгариф”нәшрияты, 2008.

5. Сафиуллина Ф.С., Фәтхуллова К.С. Рустелендәсөйләшүчебалаларга татар теле укытупрограммасы. Казан, “Мәгариф”нәшрияты , 2008.

6. Хәйдарова Р.З., Малафеева Р.Л.. Рустелендәсөйләшүчебалаларга татар әдәбияты укытубуенчасынапкарау программасы.1-11. Казан, “Мәгариф”нәшрияты ,2007ел.